**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2020 елның 15 июне** **№ 152**

**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясындагы 1 өлеше, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 16 статьясына нигезендә, Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ**:

1. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:
- Осинники п., Яшьләр урамы, 9А йорт (административ бина);
- Осинники п., Лесная ур., 2 йорт (Осинники авыл мәдәният йорты),
3. Әлеге карарны “Идел таңнары” газетасында кабул ителгән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы**
**муниципаль районы Осинники**
**авыл җирлеге башлыгы,**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы**
**муниципаль районы**
**Осинники авыл җирлеге Советы рәисе** **А.Х. Сәгъдеев**